МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.05.2018 г. Казань № под-818/18

"Төбәкара инновацион
мәйданчыклар төзү
һәм аларга ярдәм итү"
гранты турында

1. "Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү һәм аларга ярдәм итү" гранты булдыру.

2. "Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү һәм аларга ярдәм итү" гранты турындагы нигезләмәне расларга.

3. Өстәмә һөнәри белемне үстерү бүлегенә (Р. И. Шәяхмәтова):

3.1. 2018 нче елның 15 июненнән 9 июленә кадәр электрон мәйданчыкта оешмалар арасында "Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү һәм аларга ярдәм итү" грантын алу өчен сайлап алу бәйгесе оештырырга.

3.2. Приказ чыгарылганнан соң, өч көн эчендә (эш көнен исәпләп) ТР юстиция министрлыгына дәүләт регистрациясенә җибәрергә.

4. Дәүләт автоном мәгариф учреждениесе өстәмә һөнәри белем бирүче "ТР Мәгарифне үстерү институты"на (Л. Н. Ногманова) электрон мәйданчыкта грант алучыларны сайлап алу барышын мәгълүмати-методик яктыртырга.

5. Хисап бүлегенә (Г.К.Мөхәммәткәримова) грант алу өчен сайлап алу бәйгесе җиңүчеләренә грантны түләп бетерү өчен акча күчерү эшен ТР Министрлар Кабинеты раслаган башка төрле формада икенче төрле бюджетара трансфертлар тәртибендә оештырырга.

6. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән көченә керә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары И.Г.Хадиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр
урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
боерыгы нигезендә расланган
10.05.2018
№ под-818/18

“Төбәкара инновацион мәйданчыклар булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү” турында грант нигезләмәсе

1. Гомуми нигезләмә

1.1. “Төбәкара инновацион мәйданчыклар булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү” (алга таба грант) турында грант Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә раслана.

Чараның катнашучылары - грант бирүче, грант алуга дәгъва белдерүче, грант отучы.

Грант бирүче - грантларны тәкъдим итүгә вәкаләт белдерүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – министрлык).

Грантка дәгъва кылучы белем бирү оешмаларына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына караган Экспертлар киңәшмәсе карары нигезендә инновацион проектны (программаларны) тормышка ашыруда төбәкара инновацион мәйданчыклар статусы бирелә.

Конкурста Татарстан Республикасының 2018 нче елда белем бирү системасында приоритетлар юнәлешендә инновацион эшчәнлекне тормышка ашыручы ике төрдәге төбәкара инновацион мәйданчыклар катнаша ала (нигезләмәгә 1 нче кушымта):

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт белем бирү оешмалары, югары, һөнәри, педагогик профильдәге өстәмә һөнәри белем бирү – фәнни консультантлар (алга таба – беренче төр инновацион мәйданчыклар). Беренче төр инновацион мәйданчыклар педагогия хезмәткәрләре һәм белем бирү оешмалары өчен фәнни консультант булып тора;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү программалары, урта, балаларга өстәмә белем бирү, фәнни консультантлар һәм апробацион мәйданчыклар белән берләшеп эшләүче (алга таба - икенче төр мәйданчыклар).

Беренче төр мәйданчыклар булып фәнни җитәкчелекне тормышка ашыручы һәм педагогик хезмәткәрләрнең, белем бирү оешмаларының инновацион эшчәнлеге белән бергә индивидуаль, төркемдә, командада һәм коллектив формада материаль-техник, хәзерлекле, методик, информацион ресурслар санала;

инновацион педагогик эшчәнлекнең индивидуаль формасы педагогик хезмәткәрләрнең мөстәкыйль инновацион нәтиҗәсен таләп итә;

инновацион педагогик эшчәнлекнең төркем формасы төрле фән укытучы педагогларның бердәм мәсьәләләрен комплекслы чишәргә мөмкинлек бирә;

инновацион эшчәнлекнең команда формасы төрле белем бирү оешмаларындагы белгечләр төркеменең белем һәм тәрбия бирү өлкәсендәге проектларын тормышка ашыру өчен берләштерүне күзаллый;

инновацион эшчәнлекнең күмәк формасы белем бирү оешмалары коллективының инновацион темасы өстендә эшчәнлеген күз алдында тота.

Беренче төр инновацион мәйданчыкларның төп вазыйфасы:

белем бирү өлкәсендә инновацион яңалыкларны тирәнтен өйрәнү;

педагогия хезмәткәрләренә һәм белем бирү оешмаларының эшчәнлегенә фәнни-методик ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы белем бирү системаларын апробацияләү һәм инновацион педагогик яңалык кертү;

иң яхшы инновацион белем бирүче практика диссеминациясе өчен шартлар тудыру;

Татарстан Республикасының белем бирү системасына тәкъдим ителгән тема юнәлешендә инновацияләрне кертү;

“Төбәкара инновацион мәйданчыклар булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү” (алга таба – Экспертлар киңәшмәсе) грантын инновацион күзаллауның координацион эшчәнлеге, инновацион мәйданчыкларның үзара килешеп эшләве, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы экспертлар киңәшмәсе тарафыннан тормышка ашырыла.

Беренче төр инновацион мәйданчыклар өчен төп шартлар:

партнер оешмалар (апробацион мәйданчыклар) булу;

мониторингларны апробацияләү өчен әсбаплар булу һәм инновацияләрне тормышка ашыру;

инновацион эшчәнлек буенча локаль документлар булу һәм электрон система ярдәмендә башкару;

тәкъдим ителгән темага белгечләрнең квалификацияләре туры килү һәм аларның җитәрлек булуы;

инновацион эшчәнлек буенча тәкъдим ителгән темага фәнни һәм практик эшләрнең булуы шәхси, группада, командада һәм коллектив формаларда тормышка ашыру;

мәктәпкәчә, гомумбелем, урта һөнәри, өстәмә белем бирү оешмаларындагы челтәрле инновацион проектларны тормышка ашыруда фәнни консультацияләр үткәрү.

Инновацион мәйданчыкларның икенче төре булып Татарстан Республикасының белем бирү системасындагы актуаль проблемалар буенча белем бирү эшчәнлеген, методик һәм фәнни тикшеренүнең гамәли характерын тормышка ашыручы оешма таныла.

Икенче төр инновацион мәйданчыклар инновацион эшчәнлеген беренче төр инновацион мәйданчыклар белән үзара бәйләнештә тормышка ашыра.

Икенче төр инновацион мәйданчыкларның төп бурычы:

Татарстан Республикасының белем бирү системасындагы актуаль проблемаларны беренче төр инновацион мәйданчыклар белән берлектә үстерү, гамәли характердагы методик, тикшеренү эшләрен оештыру һәм үткәрү;

гамәли характердагы инновацион яңалык булдыру;

белем бирү һәм апробацион мәйданчыкларның практик эшенең уңай йогынтысы нигезендә инновацион нәтиҗәне күзаллау.

Икенче төр инновацион мәйданчыклар өчен төп шартлар:

фәнни консультантлар булу;

партнер оешмалар ( апробацион мәйданчыклар булу);

мониторингларны апробацияләү өчен әсбаплар булу һәм инновацияләрне тормышка ашыру;

тәкъдим ителгән темага белгечләрнең квалификацияләре туры килү һәм аларның җитәрлек булуы;

инновацион эшчәнлек буенча тәкъдим ителгән темага практик эшләрнең булуы;

оешманың инновацион эшчәнлегенең күмәк формасы.

Икенче төр инновацион мәйданчыклар булып танылган грантка дәгъва белдерүчеләр Татарстан Республикасының белем бирү системасы үсешенең актуаль проблемалары буенча гамәли характердагы методик һәм фәнни тикшеренү эшләрен апробацион мәйданчыклар (белем бирү оешмалары) һәм фәнни консультантлар белән берлектә оештыра, еллык эш планы белән берлектә киләсе елның 1 нче гыйнварына кадәр инновацион яңарышны тирәнтен тикшереп Министрлыкка җибәрә.

Һәр төр грантка дәгъва кылучылар еллык эш планына таянып, Татарстан Республикасының белем бирү системасындагы педагогларның һөнәри үсеше һәм методик ярдәме нәтиҗәсендә белем бирү өлкәсендәге инновацияләрне тормышка ашыруны оештыра.

Конкурска сайлап алу нәтиҗәләре буенча 1 нче урыннан 8 нче урынга кадәрге беренче төр инновацион мәйданчыклар, яки конкурс нәтиҗәләре буенча 1 нчедән 24 нче урынга лаек дип танылган икенче төр инновацион мәйданчыклар грант отучы белем бирү оешмасы дип таныла.

Грант грант отучыларга акчалата бер тапкыр бирелә:

1нче урыннан 8 нче урынга кадәр беренче төр инновацион мәйданчыкларга 1 000 000 сум күләмендә (бер миллион);

1 нче урыннан 24 нче урынга лаек булган икенче төр инновацион мәйданчыкларга 500 000 сум күләмендә ( биш йөз мең).

Грант түләү түбәндәгеләргә тотыла:

Фәнни консультант, мәйданчыкта эшләүчеләргә (инновацион мәйданчык җитәкчесе урынбасары, фән укытучылары, класс җитәкчесе яки оешма методисты), инновацион продукт эшләү өчен (укыту-методик комплектлар, ярдәмлекләр, программалар, диагностик һәм контроль-бәяләү материаллары һ.б.) – 80 %

Инновацион продуктны басу һәм тиражлау өчен (10%);

Инновацион тәҗрибә белән уртаклашу өчен тотылган чыгымнар (10%).

Грант алучыларны сайлап алу конкурс нигезендә бара (алга таба – конкурс).

1.1. Грант алучылар өчен конкурсның максаты – белем бирү оешмаларында инновацион эшчәнлекне стимуллаштыру, Татарстан Республикасында белем бирү сыйфатын арттыру.

1.2. Конкурсның бурычы – Татарстан Республикасында белем бирүнең приоритетлы юнәлешлеләрендә тәкъдим ителгән инновацион продуктның сыйфаты һәм әһәмиятлелеген билгеләү.

1.3. Инновацион продукт – инновацион эшчәнлекнең соңгы нәтиҗәсе, ул яңа яки камилләштерелгән продукт, яки практик эшчәнлек вакытында кулланыла торган технологик процесс.

1.4. Инновацион продуктның төп төрләре:

методика һәм технологияләр;

методик тәкъдимнәр, ярдәмлекләр;

белем бирү процессын оештыру модельләре;

белем бирү нәтиҗәләрен бәяләүнең мониторингы;

белем бирү, укыту, коррекцион, профилактик программалар;

укыту-методик комплектлар;

диагностик, контроль-бәяләү материаллары;

социаль партнерлаштыру оештыруның моделе.

1.5. Конкурс ике этапта үткәрелә:

Грант алуга дәгъва белдерүчеләрдән башка (Читтән торып) – белем бирү оешмаларында инновацион эшчәнлеген проектлаштыру өчен документлар тапшыру;

Грант алуга дәгъва белдерүчеләр катнашында (турыдан-туры) – Татарстан Республикасында белем бирү үсешендә актуаль юнәлешләр буенча инновацион эшчәнлек проектын яклау.

1.6. Конкурста катнашу өчен беренче төр инновацион мәйданчык статусына грант алуга дәгъва белдерүче:

мөстәкыйль рәвештә апробацион мәйданчыклар һәм өч приоритетлы инновацион эшчәнлек юнәлешләрен сайлый;

2.3. пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тутыра һәм аларны Эскпертлар киңәшмәсендә карау өчен нигезләмәдә күрсәтелгән вакыттан соңга калмыйча электрон мәйданчыкта урнаштыра.

1.7. Конкурста катнашу өчен икенче төр инновацион мәйданчык статусына грант алуга дәгъва белдерүче:

мөстәкыйль рәвештә фәнни консультанты, апробацион мәйданчыкны һәм инновацион эшчәнлекнең приоритетлы юнәлешләренең берсен сайлый;

2.4. пунктында күрсәтелгән документлар пакетын тутыра һәм аларны Эскпертлар киңәшмәсендә карау өчен нигезләмәдә күрсәтелгән вакыттан соңга калмыйча электрон мәйданчыкта урнаштыра.

1.8. Конкурсның грант алуга дәгъва белдерүчеләрдән башка уздырылган этабы 8 нче кушымтада китерелгән критерийләр белән бәяләнә.

1-3 критерийләре буенча бер күрсәткеч бәяләнә һәм 0дән алып 2 баллга хәтле куела. 4-5 критериясе буенча бөтен күрсәткечләр дә бәяләнә, 0 дән 1гә кадәр балл куела. Бөтен критерийләрдәге баллар саны кушыла. Гомуми баллар саны беренче төр инновацион мәйданчыклар өчен 13 баллдан, икенче төр инновацион мәйданчыклар өчен 12 баллдан артмаска тиеш.

Экспертлар киңәшмәсе куйган баллар суммасы буенча грант алуга дәгъва белдерүчеләр рейтингы формалаштырыла.

Конкурсның грант алуга дәгъва белдерүчеләрдән башка уздырылган беренче этабы җиңүчеләре булып рейтингта 1 дән алып 50 урын алучылар санала.

Экспертлар киңәшмәсе беренче этап нәтиҗәләре буенча бер хокуклы (приоритетсыз) булган грант алуга дәгъва белдерүчеләр исемлеген төзи, алар конкурсның икенче этабында катнаша алалар.

1.9. Конкурсның грант алуга дәгъва белдерүчеләр катнашында узачак этабы инновацион эшчәнлекнең проектын яклау формасында уза.

Проектны оешма җитәкчесе презентация формасында яклый (электрон форматта). Проектны яклау өчен 10 минут вакыт бирелә.

Проектны яклау этабына белем бирү оешмасы инновацион продукт турында мәгълүмат китерә.

Инновацион продукт турында мәгълүматта түбәндәгеләр яктыртыла:

инновацион продуктка аннотация (инновацион продуктның уникальлеге, актуальлеге һәм фәнни-техник яңалыгы, социаль-экономик әһәмияте, конкурентлыкка сәләтле), ирекле формада языла;

интеллектуаль яктан хокуклы булуны раслаучы документлар (булган очракта);

Microsoft Office Power Point программасында инновацион продуктның фотолары белән эшләнгән презентация.

инновацион продукт электрон флешка белән Экспертлар киңәшмәсенә бирелә.

Конкурсның икенче этабы критерийләре түбәндәгеләр:

продуктның актуальлеге (эшләүдә нигезчәнлек, яңалык);

Татарстан Республикасының белем бирү системасы үсешенә юнәлдерелгән инновацион продукт;

тасвирлауның концептуальлеге һәм системалылыгы;

инновацион продуктны кулланганда уңай нәтиҗәләргә ирешү;

универсальлек (практикада киң куллану мөмкинлеге).

Һәр критерий өчен 1дән алып 5кә кадәр балл куела һәм баллар суммасы кушыла. Гомуми балл 25 баллдан артмаска тиеш.

Эксперт киңәшмәсе конкурста оешмаларга һәр критерий буенча баллар куя, шуның нәтиҗәсендә грантка тәкъдим ителүчеләр рейтингы төзелә.

## 2. Конкурста катнашу өчен документлар пакетын урнаштыру тәртибе

2.1. Конкурста катнашу өчен грант алуга дәгъва белдерүче документлар пакетын www.riprt.ru адресы буенча электрон мәйданчыкка 2018 нче елның 15 нче июненә кадәр урнаштыра: (алга таба – электрон мәйданчык).

2.2. Әгәр документлар пакеты 2018 нче елның 15 июньненнән соңрак бирелсә, грантка алуга дәгъва белдерүче конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.3. Беренче төр инновацион мәйданчык статусына грант алуга дәгъва белдерү өчен белем бирү оешмасының документлар пакетында түбәндәгеләр булырга тиеш:

экспертиза үткәрү өчен гариза (ул Эксперт киңәшмәсе рәисенең исеменә ирекле рәвештә языла);

гамәлдәге нигезләмәнең 2 нче  кушымтасына бәйле рәвештә, белем бирү оешмасы һәм инновацион эшчәнлек турында мәгълүмат;

гамәлдәге нигезләмәнең 3 нче кушымтасына бәйле рәвештә, алдан техник экспертиза үткәрү бите;

беренче төр инновацион мәйданчык статусына дәгъва белдерүчеләр өчен инновацион эшчәнлекне тасвирлау (программа, технология һ.б.) электрон формада, 5 биткә кадәр, гамәлдәге нигезләмәнең 4 нче кушымтасына бәйле рәвештә, ирекле формада языла;

гамәлдәге нигезләмәнең 8 нче кушымтасына бәйле рәвештә, инновацион мәйданчык статусына дәгъва кылучының үзбәясе;

2.4. Икенче төр инновацион мәйданчык статусына грант алуга дәгъва белдерү өчен белем бирү оешмасының документлар пакетында түбәндәгеләр булырга тиеш:

экспертиза үткәрү өчен гариза (ул Эксперт киңәшмәсе рәисенең исеменә ирекле рәвештә языла);

гамәлдәге нигезләмәнең 5 нче кушымтасына бәйле рәвештә, белем бирү оешмасы турында мәгълүмат һәм инновацион эшчәнлек турында белешмә;

тасвирлауда муниципаль берәмлек (бүлек) икенче төр инновацион мәйданчык статусына дәгъва белдерүче һәр белем бирү оешмасы эшчәнлегенә аргументлаштырылган бәя бирә (ирекле рәвештә);

гамәлдәге нигезләмәнең 6 нчы кушымтасына бәйле рәвештә, алдан техник экспертиза үткәрү бите;

гамәлдәге нигезләмәнең 7 нче кушымтасына бәйле рәвештә, электрон вариантта 5 бит күләмендә, икенче төр инновацион мәйданчык статусына туры китереп, оешманың инновацион эшчәнлеге турында тасвирлама;

гамәлдәге нигезләмәнең 8 нче кушымтасына бәйле рәвештә, дәгъвачының инновацион статусына үзбәя.

## 3. Конкурсның сайлап алу турын үткәрү тәртибе

3.1. Грант алуга дәгъва белдерүче документлар кабул итү вакыты тәмамланырга 5 көннән дә соңга калмыйча, конкурсның сайлап алу туры үткәрелү турында Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендәге рәсми сайтында (алга таба –Министлыкның рәсми сайты) “Программалар, проектлар һәм чаралар” бүлегендә, “Укытучыларга грантлар” бүлекчәсендә мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итә.

3.2. Конкурста катнашучылар документларны 2018 нче елның 15 нче июненә кадәр тапшыра.

3.3. Конкурс материалларын Экспертлар киңәшмәсе бәяли.

3.4. Экспертлар киңәшмәсе 38 кешедән тора: киңәшмә рәисе, рәис урынбасары, сәркатиб һәм киңәшмә әгъзалары.

3.5. Экспертлар киңәшмәсе эшенә инновацион эшчәнлек өлкәсендә махсус белемле Мәгариф һәм гыйльми оешмалар, җәмгыять оешмалары һәм берләшмәләре белгечләре тартылырга; шулай ук эксперт эшендә тәҗрибәсе булган, квалификациясе туры килгән белгечләр җәлеп ителергә мөмкин.

3.6. Экспертлар киңәшмәсенең яртысыннан артыгы тавыш бирсә, карар кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, мәсьәләне рәис хәл итә. Экспертлар киңәшмәсе эшенә җәлеп ителгән белгечләр тавыш бирүдә катнашмыйлар.

3.7. Конкурс материалларын тикшергәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

конкурска тәкъдим ителгән материалларны гадел рәвештә, бәяләү критерийларына тулысынча туры китереп бәяләү;

яшерен рәвештә (шул ук вакытта эксперт әгъзалары да аерым рәвештә катнашучының эшен бәяләүдә катнашырга тиеш түгел).

3.8. Экспертлар киңәшмәсе:

читтән торып һәм турыдан-туры турларда үткәрелгән конкурс материалларын һәм эшләрне Нигезләмәдә күрсәтергән вакытка һәм барлык таләпләргә туры китереп, Нигезләмәнең 8 кушымтасында күрсәтелгәнчә бәяләргә;

баллар эксперт кәгазенә төшерелә, эксперт имзасы белән раслана һәм Экспертлар киңәшмәсе рәисенә тапшырыла;

эксперт кәгазьләре нигезендә конкурста катнашучылар рейтингы төзелә.

3.9. Экспертлар киңәшмәсе 2018 нче елның 15 нче июненнән 25 июненә кадәр тапшырылган документларны карый, конкурста читтән торып (заочный) катнашу этабына килгән эшләрне тикшерә.

3.10.Экспертлар киңәшмәсенең 2018 нче елның 25 июненнән 27 июньгә кадәр башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, конкурста турыдан-туры (очный) катнашучылар исемлеге төзелә һәм раслана.

3.11.Конкурсның сайлап алу этабы 2018 нче елның 28-29 нчы июнь көннәрендә үткәрелә. Экспертлар киңәшмәсенең эш нәтиҗәләре буенча конкурста катнашучылар рейтингы төзелә.

3.12.Экспертлар киңәшмәсе 2018 нче елның 2 нче июленнән 6 нчы июленә кадәр үткәрелгән конкурсның сайлап алу этабы нәтиҗәләре буенча исемлекләр төзи.

3.13.Грант тәкъдим итүче 2018 нче елның 9 июлендә грант отучыларның расланган исемлеген Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

## 4. Хисап бирү формасы һәм тәртибе

4.1. Инновацион мәйданчык булып саналган оешмалар гамәлдәге нигезләмәнең 9 нчы кушымтасы буенча инновацион эшчәнлек турында алдагы елның 1 нче мартыннан да калмыйча Министрлыкка хисап тапшыралар.

4.2. Хисап 10 бит күләмендә (динамик һәм статистик мәгълүматлар белән), инновацион эшчәнлек нәтиҗәләре турында аналитик белешмәне үз эченә ала (программа һәм чыгымнар буенча хисап).

4.3. Эксперлар киңәшмәсе гамәлдәге нигезләмәнең 10 нчы кушымтасы буенча инновацион проектны тормышка ашыру буенча хисап материалларына бәя бирә.

## 5. Чараларны финанслау

5.1. Грант бирү максатыннан субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасының Министерлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Кушымта 1
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы нигезләмәгә

Татарстан Республикасы мәгариф системасында беренче төр инновацион эшчәнлек юнәлешләре исемлеге

Мәктәпкәчә белем бирү:

1. Белем бирү сыйфатын бәяләүнең региональ сыйфатын формалаштыру.
2. Мәктәпкәчә беле бирүдә инклюзия һәм дәвамчанлык мәсьәләсе.
3. Мәктәпкәчә яшьтәге баланың интеллектуаль һәм полилингваль үсеше.

Гомуми белем бирү:

1. Белем бирү сыйфатын бәяләүнең региональ системасын үстерү: региональ проектларны тормышка ашыру юлы белән, белем бирү сыйфаты түбән булган һәм социаль шартлар начар булган мәктәпләрдә белем бирү сыйфатын күтәрү. Мәктәпнең эчке белем бирү сыйфаты бәяләү системасы.
2. Чит телдә белем бирү системасын модернизацияләү.
3. Көчле мотивацияле һәм сәләтле балалар белән эшләүне камилләштерү.
4. ФДББС тормышка ашыру шартларында яңа педагогик технологияләр кертү.
5. Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен башлангыч гомуми белем бирү стандартлары, акыл ягыннан артта калган балалар өчен федераль белем бирү стандартлары кертү. Заманча мәктәпләргә инклюзив белем бирүне кертү. Җайлашкан программаларны (79 ст.1 п. 273- ФЗ туры китереп) тормышка ашыру.
6. Мәгълүмат-китапханә үзәкләре булдыру.
7. Авыл мәктәпләрендә инновацион проектларны тормышка ашыру.
8. Укучыларны тәрбияләү һәм социальләштерүдә инновацион программаларны тормышка ашыру.
9. Татарстан Республикасында профильле укытуны: ”мәктәп-колледж-вуз-предприятие” системасы бәйләнешен тормышка ашыру.
10. Заманча белем бирүдә остазлыкның роле.

Өстәмә белем бирү:

1. Балаларның техник иҗатын үстерү буенча программалар эшләү.
2. Яраклаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыру.
3. Өстәмә белем бирү учрежденияләрендә шәхескә юнәлдерелгән технологияләрне финанслауны кертү.

Һөнәри белем бирү:

1. Урта һөнәри белем бирү оешмаларында бердәм белем бирү программаларын эшләү.
2. Бердәм белем бирү программаларын үзләштерүне бәяләү өчен бердәм фонд булдыру.
3. Һөнәри һәм World Skills стандартларын һөнәри белем бирү учрежденияләрендә гамәлгә кертү.
4. Һөнәрләр һәм белгечлекләрдә ФДБСын кертү.

Кушымта 2
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү
һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы
нигезләмәгә

“Беренче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмалар өчен электрон мәйданга куелырга тиешле документлар пакеты

<u>1.Белем бирү оешмасы турында мәгълүмат</u>

Оешманың тулы исеме
Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
Оешманың телефоны/факсы
Оешманың электрон адресы
Оешманың интернетта бите (инновацион продукт турында мәгълүмат бирелгән битне күрсәтү)

<u>2. Инновацион эшчәнлек турында мәгълүмат</u>
Инновацион эшчәнлекнең темасы
Педагогик инновацияләр өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр турында шәхси мәгълүмат
Инновацион эшчәнлекне ресурслар белән тәэмин итү (материаль-техник, финанслау, кадрлар, укыту-методик)
Актык инновацион продукт формасы (кулланма, тәкъдимнәр, программа, технологияләр, модельләр, контроль бәяләү материаллары һ.б.).

** Мәгълүмати материаллар doc форматында, Times New Roman шрифтында, 14 кегль, 1,5 интервал, ян-яктан – 2 см бирелә. Материалларның күләме 20 биттән артмаска тиеш.*

__________________________ ____________________
оешма җитәкчесенең имзасы имзаны шәрехләү
Мөһер сугу урыны

Кушымта 3
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү
һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы
нигезләмәгә

“Беренче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмалар өчен алдан техник тәҗрибә үткәрү бите

| № | Техник тәҗрибә параметрлары | Әйе/юк (дәгъвачы тарафыннан тутырыла ) | Әйе/юк (эксперт тарафынна н тутырыла ) |
|---|---|---|---|
| | Материалларның булуы | | |
| 1. | Белем бирү оешмасы турында мәгълүмат | | |
| 2. | Инновацион эшчәнлек барышында тәҗрибә мәйданын бирергә әзер булучы белем бирү оешмалары турында мәгълүмат | | |
| 3. | Инновацион эшчәнлекнең темасы | | |
| 4. | Педагогик инновацияләр өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр турында шәхси мәгълүмат | | |
| 5. | Материаль-техник яктан тәэмин итү | | |
| 6. | Финанслау (смета) | | |
| 7. | Кадрлар белән тәэмин итү | | |
| 8. | Укыту-методик яктан тәэмин итү | | |
| 9. | Инновацион эшчәнлек турында мәгълүмат | | |
| 9.1 | Булган охшашлыкларның анализы һәм аларның чикләнгәнлеген нигезләү (актуальләштерү) | | |
| 9.2 | Максат һәм бурычлар | | |
| 9.3 | Контингент | | |
| 9.4 | Инновацион эшчәнлек эчтәлегенә кыскача аннотация | | |
| 9.5 | Көтелгән нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат ягыннан) | | |
| 9.6 | Инновацион эшчәнлекнең эффектлылыгын тикшерү мониторингы кораллары | | |
| 9.7 | Инновацион продукт | | |
| 9.8 | Инновацион продуктны кертү куркынычы | | |
| 9.9 | Үсеш перспективалары | | |
| 10. | Материалларның тәҗрибә таләпләренә туры килүе | | |
| 11. | Техник тәҗрибә нәтиҗәләре | | |
| Конкурска кертелә (әйе) | | Конкурска кертелми (юк) | |

Тәҗрибә үткәрүнең көне:
Оешма җитәкчесенең ФИО_____________
Экспертның ФИО __________________

Кушымта 4
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү
һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы
нигезләмәгә

“Беренче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмаларның инновацион эшчәнлеген тасвирлау

Тасвирлауның төп бүлекләре:

Булган охшашлыкларның анализы һәм аларның чикләнгәнлеген нигезләү (актуальләштерү)
Максат һәм бурычлар
Контингент
Инновацион эшчәнлек эчтәлегенә кыскача аннотация
Көтелгән нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат ягыннан)
Инновацион эшчәнлекнең эффектлылыгын тикшерү мониторингы кораллары
Инновацион продукт
Инновацион продуктны кертү куркынычы
Үсеш перспективалары

** Материаллар doc форматында, Times New Roman шрифтында, 14 кегль, 1,5 интервал, ян-яктан – 2 см бирелә. Күләме 5 биттән артмаска тиеш.*

Кушымта 5
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү
һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы
нигезләмәгә

“Икенче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмалар өчен электрон мәйданга куелырга тиешле документлар пакеты

1.Белем бирү оешмасы турында мәгълүмат

Оешманың тулы исеме
Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
Оешманың телефоны/факсы
Оешманың электрон адресы
Оешманың интернетта бите (инновацион продукт турында мәгълүмат бирелгән битне күрсәтү)
Фәнни консультант турындм мәгълүмат
Инновацион эшчәнлек турында белешмә
Инновацион эшчәнлекнең темасы
Авторлар коллективы
Инновацион эшчәнлекне ресурслар ягыннан тәэмин итү (материаль-техник, финанслау, кадрлар, укыту-методик)
Инновацион продуктның соңгы формасы (ярдәмлек, тәкъдимнәр, программа, модельләр, контроль-бәяләү материаллары һ.б.)

Икенче төр инновацион мәйданчык статусына дәгъва кылучы белем бирү оешмаларын тасвирлауда белем бирүче оешмага аргументлаштырылган бәя (ирекле формада) урын ала.

** Мәгълүмати материаллар doc форматында, Times New Roman шрифтында, 14 кегль, 1,5 интервал, ян-яктан – 2 см бирелә. Материалларның күләме 20 биттән артмаска тиеш.*

| | |
|---|---|
| Фәнни консультант имзасы ______________ | ______________ имзаны шәрехләү |
| Оешма җитәкчесе имзасы ______________ | ______________ имзаны шәрехләү |

Кушымта 6
“Төбәкара инновацион мәйданны
булдыру һәм ярдәм итү” гранты
турындагы нигезләмәгә

## “Икенче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмалар өчен алдан техник экспертиза үткәрү бите

| № | Техник тәҗрибә параметрлары | Әйе/юк (дәгъвачы тарафыннан тутырыла ) | Әйе/юк (эксперт тарафыннан тутырыла ) |
|---|---|---|---|
| Материалларның булуы | | | |
| | Оешма турында мәгълүмат | | |
| | Фәнни консультант турында мәгълүмат | | |
| | Инновацион эшчәнлек барышында тәҗрибә мәйданын бирергә әзер булучы белем бирү оешмалары турында мәгълүмат | | |
| | Инновацион эшчәнлекнең темасы | | |
| | Авторлар коллективы | | |
| | Материаль-техник яктан тәэмин итү | | |
| | Финанслау (смета) | | |
| | Кадрлар белән тәэмин итү | | |
| | Укыту-методик яктан тәэмин итү | | |
| . | Инновацион эшчәнлек турында мәгълүмат | | |
| 10.1 | Булган охшашлыкларның анализы һәм аларның чикләнгәнлеген нигезләү (актуальләштерү) | | |
| 10.2 | Максат һәм бурычлар | | |
| 10.3 | Контингент | | |
| 10.4 | Инновацион эшчәнлек эчтәлегенә кыскача аннотация | | |
| 10.5 | Көтелгән нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат ягыннан) | | |
| 10.6 | Инновацион эшчәнлекнең эффектлылыгын тикшерү мониторингы кораллары | | |
| 10.7 | Инновацион продукт | | |
| 10.8 | Инновацион продуктны кертү куркынычы | | |
| 10.9 | Үсеш перспективалары | | |
| 11. | Материалларның тәҗрибә таләпләренә туры килүе | | |
| 12. | Техник тәҗрибә нәтиҗәләре | | |
| Конкурска кертелә (әйе) | | Конкурска кертелми (юк) | |

Тәҗрибә үткәрүнең көне:
Оешма җитәкчесенең ФИО______________
Экспертның ФИО ____________________

Кушымта 7
“Төбәкара инновацион мәйданны
булдыру һәм ярдәм итү” гранты
турындагы нигезләмәгә

“Икенче төр инновацион мәйдан” статусына дәгъва кылучы оешмаларның инновацион эшчәнлеген тасвирлау

Тасвирлауның төп бүлекләре:

Булган охшашлыкларның анализы һәм аларның чикләнгәнлеген нигезләү (актуальләштерү)
Максат һәм бурычлар
Контингент
Инновацион эшчәнлек эчтәлегенә кыскача аннотация
Көтелгән нәтиҗәләр (сан һәм сыйфат ягыннан)
Инновацион эшчәнлекнең эффектлылыгын тикшерү мониторингы кораллары
Инновацион продукт
Инновацион продуктны кертү куркынычы
Үсеш перспективалары

** Материаллар doc форматында, Times New Roman шрифтында, 14 кегль, 1,5 интервал, ян-яктан – 2 см бирелә. Материалларның күләме 5 биттән артмаска тиеш.*

Кушымта 8
“Төбәкара инновацион мәйданны
булдыру һәм ярдәм итү” гранты
турындагы нигезләмәгә

## Беренче төр инновацион мәйданчык статусына ия булу өчен бәяләү критерийләре

Мәгариф оешмасының исеме______________________________________
Инновацион эшчәнлекнең темасы
Инновацион продуктның исеме, инновацион продуктның формасы
_______________________________________________________________

| Бәяләү критерийләре | | Бәяләү күрсәткечләре | | Претендентның үзбәясе | Эксперт бәясе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәкъдим ителгән продуктның инновацион характерда булуы (бер күрсәткеч бәяләнә) | 1.1 | Өр-яңа продукт (инновация) тәкъдим ителгән | 2 | |
| | | 1.2 | Билгеле булган методлар, технологияләр, программалар һ.б.ш. шактый үзгәртелгән, камилләштерелгән продукт тәкъдим ителгән (новация) | 1 | |
| | | 1.3 | Билгеле булган продукт тәкъдим ителгән (инновацион булмаган) | 0 | |
| 2 | Инновацион продуктның ТР мәгариф системасы үсешенең актуаль мәсьәләләрен чишүгә юнәлгәнлеге (бер күрсәткеч бәяләнә) | 2.1 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен комплексы чишәргә мөмкинлек бирә (шактый зур тәэсир итә) | 2 | |
| | | 2.2 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен чишүгә юнәлтелгән (өлешчә тәэсир итә) | 1 | |
| | | 2.3 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен чишәргә ярдәм итми ( тәэсире юк) | 0 | |
| 3 | Инновацион продуктны кулланганда ирешелгән нәтиҗәләрнең актуальлеге (бер күрсәткеч бәяләнә) | 3.1 | Инновацион продукт барлык мәгариф оешмалары өчен дә кулланырга яраклы | 2 | |
| | | 3.2 | Инновацион продукт бер типтагы мәгариф оешмалары төркеме өчен кулланырга яраклы (мәсәлән, гимназияләр, гомуми белем бирү мәктәпләре, коррекцион мәктәпләр һ.б.ш.) | 1 | |
| | | 3.3 | Инновацион продукт белем бирү практикасында актуаль нәтиҗәләргә ирешүгә китерми | 0 | |
| 4. | Инновацион эшчәнлекне тормышка ашыруның ресурслар белән тәэмин ителеше (барлык күрсәткечләр бәяләнә) | 4.1 | Партнер оешмалар булу (Апробация мәйданчыклары) | 1 | |
| | | 4.2 | Инновацияне тормышка ашыру һәм апробацияләүнең мониторингы инструментлары булу | 1 | |
| | | 4.3. | Инновацион эшчәнлекнең локаль документлары булуы һәм электрон рәвештә яктыртылу системасы булуы | 1 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Инновацион эшчәнлекне тормышка ашыруның шартлары һәм алшартлары ( барлык күрсәткечләр бәяләнә) | 5.1. | Белгечләрнең һөнәри квалификациясе алынган темага туры килүе һәм аларның җитәрлек булуы | 1 | |
| | | 5.2 | Инновационной эшчәнлеккә алынган тема буенча фәнни һәм практик эшкәртмәләр булуы | 1 | |
| | | 5.3 | Инновацион эшчәнлекнең индивидуаль, төркем, команда, коллектив формаларын тормышка ашыру | 1 | |
| | | 5.4 | Мәктәпкәчә, гомуми белем, махсус урта белем, өстәмә белем бирү оешмаларының челтәрле инновацион проектларын тормышка ашыруда фәнни консультант | 1 | |

**Экспертның аерым фикере:**

Инновацион продуктка гомуми бәя: (max балл - 13)

Эксперт имзасы ______________________________/______________________________/

Экспертиза үткәрү датасы____________________________________________________

# Икенче төр инновацион мәйданчык статусына туры килүне билгеләү критерийләре

Мәгариф оешмасының исеме_____________________________________
Инновацион эшчәнлекнең темасы
Инновацион продуктның исеме, инновацион продуктның формасы
_____________________________________________________________________________

| Бәяләү критерийләре | | Бәяләү күрсәткечләре | | Претендентның үзбәясе (һәр критерий буенча бер күрсәткечне билгеләгез) | Эксперт бәясе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәкъдим ителгән продуктның инновацион характерда булуы (бер күрсәткеч бәяләнә) | 1.1 | Өр-яңа продукт (инновация) тәкъдим ителгән | 2 | |
| | | 1.2 | Билгеле булган методлар, технологияләр, программалар һ.б.ш. шактый үзгәртелгән, камилләштерелгән продукт тәкъдим ителгән (новация) | 1 | |
| | | 1.3 | Билгеле булган продукт тәкъдим ителгән (инновацион булмаган) | 0 | |
| 2 | Инновацион продуктның ТР мәгариф системасы үсешенең актуаль мәсьәләләрен чишүгә юнәлгәнлеге (бер күрсәткеч бәяләнә) | 2.1 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен комплекслы чишәргә мөмкинлек бирә (шактый зур тәэсир итә) | 2 | |
| | | 2.2 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен чишүгә юнәлтелгән (өлешчә тәэсир итә) | 1 | |
| | | 2.3 | Инновацион продуктны куллану мәгарифне үстерү мәсьәләләрен чишәргә ярдәм итми ( тәэсире юк) | 0 | |
| 3 | Инновацион продуктны кулланганда ирешелгән нәтиҗәләрнең актуальлеге (бер күрсәткеч бәяләнә) | 3.1 | Инновацион продукт барлык мәгариф оешмалары өчен дә кулланырга яраклы | 2 | |
| | | 3.2 | Инновацион продукт бер типтагы мәгариф оешмалары төркеме өчен кулланырга яраклы (мәсәлән, гимназияләр, гомуми белем бирү мәктәпләре, коррекцион мәктәпләр һ.б.ш.) | 1 | |
| | | 3.3 | Инновацион продукт белем бирү практикасында актуаль нәтиҗәләргә ирешүгә китерми | 0 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Инновацион эшчәнлекне тәэмин итү ресурслары | 4.1 | Фәнни консультантбулу | 1 | |
| | | 4.2 | Партнер-оешмалар булу | 1 | |
| | | 4.3 | Инновацияне тормышка ашыру һәм | 1 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | апробацияләү мониторингы инструменты булу | | |
| 5 | Инновацион эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар (барлык күрсәткечләр дә бәяләнә) | 5.1 | Тәкъдим ителгән тема буенча белгечләрнең һөнәри әзерлекле һәм җитәрлек булуы | | |
| | | 5.2 | Тәкъдим ителгән инновацион эшчәнлек темасы буенча фәнни һәм гамәли эшләнмәләр булу | | |
| | | 5.3 | Инновацион эшчәнлекне индивидуаль, группалап, команда белән һәм коллектив формада тормышка ашыру | | |
| | | 5.4. | Мәктәпкәчә, гомумбелем, урта һөнәри, өстәмә белем бирү оешмаларында челтәрле инновацион эшчәнлекне тормышка ашыру өчен фәнни консультант булу. | | |

**Экспертның аерым фикере** ________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

Инновацион продуктка гомуми бәя: (югары балл - 13)

Экспертның имзасы ______________________________/______________________________/

Тикшерү үткәрү вакыты______________________________________________

Кушымта № 9
“Төбәкара инновацион мәйданны булдыру һәм ярдәм итү” гранты турындагы нигезләмәгә

Инновацион мәйданчыктагы инновацион эшчәнлек нәтиҗәләре турында аналитик белешмә

Оешманың тулы атамасы
Оешма җитәкчесенең исеме, фамилиясе, отчествосы.
Тема
Фәнни җитәкченең исем, фамилиясе, отчествосы, фәнни дәрәҗәсе (атамасы)
Эш урыны
Оешманың белешмә номерлары
Оешманың интернеттагы инновацион эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүматлар урнаштырылган сайт адресы
Оешманың электрон почта адресы

1. Инновацион эшчәнлек этапларын тасвирлау (проектны тормышка ашыру программасы белән ярашлы рәвештә/ тикшеренү программасын тормышка ашыру программасы/ инновацияне диссеминацияләү программасы (инновацон продукт))
2. Инновацион эшчәнлек белән идарә итү программасы:

инновацион проектны тормышка ашыру барышында оешманың эшчәнлеген тәртипкә салу өчен эшләнгән локаль актлар исемлеге һәм аларны нигезләү;

инновацион эшчәнлекнең отчет этабын тормышка ашыру программасына кертелгән төзәтмәләр һәм инновацион эш барышының үзгәрү сәбәпләре;

башка оешмалар белән үзара бәйләнеш һәм хезмәттәшлек оештыру;

башкалар.

3. Проетта катнашучыларга характеристика (балаларның яшь һәм башка үзенчәлекләре)
4. Нәтиҗәләрне тасвирлау.
5. Алынган нәтиҗәләрнең йогынтысын дәлилләү:

диагностика методикасыннан мисаллар, бәяләү критерияләре, күрсәткечләр исемлеге (индикаторлар, параметрлар);

апробация барышында алынган эшчәнлек нәтиҗәләре буенча диагностик материалларга анализ;

инновацион эшчәнлекнең оешмаларны, гомумән, Татарстан Республикасының белем бирү системасын укыту-методик, оештыру һәм информацин тәэмин ителешенең нәтиҗәлелелеген күтәрүгә тәэсире.

6. Инновацион эшчәнлек нәтиҗәләренең ныклыгын бәяләү, тәҗрибәне күрсәтү.
7. Инновацион эшчәнлекнең үсеш мөмкинлекләрен күрсәтү.

Искәрмә:

Аналитик белешмәнең күләме А 4 форматынында 10 биттән артмаска тиеш; параметрлар түбәндәгечә: өстән – 2 см, астан – 2 см, сулдан – 2 см, уңнан – 1 см, араларындагы интервал – 1,5; шрифт - Times New Roman; зурлыгы – 12; интервал 1,5.

Кушымта һәм аналитик белешмәләрнең күләме чикләнмәгән.

Тема буенча
Тикшеренү программасы

1. Тикшеренүнең төп идеясе
2. Тикшеренүнең максатлары
3. Тикшеренүнең бурычлары
4. Тикшеренү нәтиҗәләренең Татарстан Республикасының белем бирү системасы үсеше өчен фәнни һәм гамәли кыйммәте
5. Тормышка ашыру программасы:

| Эш этаплары | Этапларның бурычлары | Эшнең төп эчтәлеге һәм эшчәнлек методлары | Эшне оештыру өчен кирәкле шартлар | Нәтиҗәләр | Нәтиҗәләрнең дөреслеген тикшерү һәм тәэмин итү чаралары | Эшне этаплап башкаруны раслаган материаллар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

1. Тикшеренү нәтиҗәсенең күрсәткечләре һәм критерия, шулай ук тикшеренү программасын тормышка ашыру барышында кулланылган мониторинг системасы
2. Тикшерүнең соңгы продуктлары
3. Тикшеренү барышында сыналган фәнни һәм укыту-методик эшләнмәләр, педагогик технологияләр, һөнәри-педагогик эшчәнлек алгоритмы.

Оешма җитәкчесе имза ФИО

Чыгымнар буенча хисап түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

Апробация мәйданчыклары персоналына, фәнни консультантка, хезмәткәрләргә түләү.

Хезмәткәрләрнең командировка чыгымнары.

Программа продуктлары, методик материаллар сатып алу өчен чыгымнар.

Инновацион тәҗрибә тиражын билгеләү һәм тарату өчен каралган чыгымнар.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына салымнар түләү, җыелган акча һәм башка түләү акчалары.

Башка түләүләр.

Соңгы исәпләүләр буенча түләп бетерү.

Чыгымнарның үзенчәлеген чагылдыручы документлар чыгымнарның төрен идентификацияләү, сыйфатын һәм күләмен ачыклау, чыгымнар турындагы

фактларны раслау( бигрәк тә материаль нәтиҗәсе булмаган эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен әһәмиятле) өчен җитәрлек күләмдә мәгълүматлы булырга тиеш. Моны раслаучы барлык түләү документлары бергә булырга тиеш. Мәсәлән: инновацион программаларны эшләгәндә һәм төзегәндә нәтиҗә булып басма текстның битләр саны гына түгел, ә программаның эчтәлеге, сыйфаты нәтиҗәлелек, ышанычлылык, перспективалылык, массакүләм практикада тормышка ашырылучанлык таләпләренә туры килергә тиеш. Шуңа күрә мондый эшләрнең бәясен исәпләү максатка ярашлы булырга, бер биткә яки эшләнгән битләр санына гына нигезләнмәскә, ә бер эш сәгатенә һәм бу эшкә тотылган чыгымнарга нигезләнергә тиеш.

10 нчы кушымта
“Төбәкара инновацион мәйданчыклар төзү
 һәм аларга ярдәм итү” гранты турындагы
нигезләмәгә

Инновацион проектны тормышка ашыру буенча отчет материалларына бәяләмә

| № | Күрсәткеч | Нәтиҗә |
|---|---|---|
| 1 | Форма буенча Ирешелгән уңышлар нәтиҗәлелеге турында отчет | |
| 1.1 | Инновацион мәйданчыкларның инновацион эшчәнлеге турында аналитик белешмә | Әйе<br>Юк |
| 1.2 | Инновация темасы буенча тикшеренү программасының барлыгы(булуы | Әйе<br>Юк |
| 1.3 | Отчетта тәкъдим ителгән нәтиҗәләрнең планлаштырылган нәтиҗәләргә туры килүе | Туры килә<br>Өлешчә туры килә<br>Туры килми |
| 1.4 | Отчетта тәкъдим ителгән нәтиҗәләрнең тасвирламасы планлаштырылган нәтиҗәләргә туры килүе | Туры килә<br>Өлешчә туры килә<br>Туры килми |
| 1.5 | Отчетта тәкъдим ителгән характеристикаларның планлаштырылган нәтиҗәләргә туры килүе | Туры килә<br>Өлешчә туры килә<br>Туры килми |
| 1.6 | Ирешелгән күрсәткечләрнең нәтиҗәлелеген раслаучы дәлилләрнең булуы | Тулысынча күрсәтелгән<br>Күрсәтелгән, ләкин тулысынча түгел<br>Күрсәтелмәгән |
| 2 | Инновацияләрне трансляцияләү һәм тиражын билгеләү | |
| 2.1 | Видеороликлар, аудиоязмалар, видеофильмнар яки интервью: саны, күләме | Әйе<br>Юк |
| 2.2 | Вебинарлар: саны, озынлыгы(озаклык | Әйе<br>Юк |
| 2.3 | Фәнни, методик мәкаләләр, кулланмалар, тәкъдимнәр һ. б. : күләме, саны | Таләпләр куелмаган<br>Бар<br>Юк |
| 2.4 | Методик күзәтүләр: (педагогик киңәшмә; фәнни-методик, фәнни-гамәли | Таләпләр куелмаган<br>Бар |

| | | |
|---|---|---|
| | конференцияләр; педагогик күргәзмә; семинар; иҗади отчет; мастер-класс; тренинглар һәм гамәли шөгыльләр) трансляцияләү дәрәҗәсе( РФ, ТР), саны | Юк |
| 3 | Инновацион эшләнмәләрне кулланганда һәм таратканда туган проблемалар | |
| 3.1 | Инновацион эшләнмәләрне кулланганда һәм таратканда туган проблемалар турында мәгълүмат | Бирелгән<br>Бирелмәгән |
| 3.2 | Инновацион эшләнмәләрне кулланганда һәм таратканда туган проблемаларны эффектив хәл итү юллары турында мәгълүматның булуы | Бирелгән<br>Бирелмәгән |
| Инновацион проектның отчет материаллары буенча үткәрелгән экспертиза нигезендә түбәндәге нәтиҗәне ясарга була:<br>Кимчелекләр: | | |